**Лубян авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28 гыйнваре 2022 ел № 1

Лубян авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварендә 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Лубян авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Лубян авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 гыйнварендә 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Лубян авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 декабрендәге 38 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы, 2019 елның 21 февралендәге 5 номерлы, 2019 елның 26 августындагы 14 номерлы, 2021 елның 22 июнендәге 11 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Г.Ф.Тежикова